Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Абалачевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
ул. Центральная д. 35, помещ.1 д.
Абалачи, Менделеевский район, 423657

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлеге
башкарма комитеты
Үзәк урамы, 35, бина 1, Абалач авылы,
Менделеевск районы, 423657

тел./факс (85549)3-65-49 Email: Abal.Men@tatar.ru

Постановление　　　　　　　　　　Карар

№ 12　　　　　　　　　　2024 елның 4 июле

Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. “Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентка үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 14 сентябрендәге 18 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
2. 2.4. пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, Россия Федерациясе законнары белән туктатып тору | а) кәгазьдә гариза биргән очракта гариза килгән көннән алып 10 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә;<br>б) электрон документ формасында гариза биргән очракта гариза килгән көннән алып 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта." | Кагыйдәләрнең 37 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкинлеге каралган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты | | |

1.2. 2.3.2. пунктын үзгәртергә һәм түбәндәгечә бәян итәргә:
«2.3.2. Адреслашу объектына яңа адрес бирелгән очракта адреслашу объектының адресын гамәлдән чыгару турындагы карар әлеге объектка яңа адрес бирү турындагы карар белән берләштерелә.»

1.3. 1.2 пунктының 10 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәгечә бәян итәргә:

"Гариза белән "Кадастр эшчәнлеге турында" Федераль законның 35 статьясында яки 42.3 статьясында каралган документ нигезендә адреслашу объекты булган тиешле күчемсез милек объектына карата кадастр эшләре яки Комплекслы кадастр эшләре башкаручы кадастр инженеры мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://prav.tatarstan.ru/ Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында mendsleevsk.tatar.ru урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Абалач авыл җирлеге башлыгы Л.А.Шияпова